**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“30” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын карары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.